КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 3 февраль г.Казань № 53

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 9 июнь, 290 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче, 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче; 2017 ел, 26 май, 310 нчы; 2018 ел, 27 ноябрь, 1060

нчы; 2020 ел, 12 март, 186 нчы, 2020 ел, 12 ноябрь, 1015 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын биләгән затлар пенсиясенә өстәмә түләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрлә-ренең тиешле елларны эшләгән өчен бирелә торган пенсияне сорап мөрәҗәгать итү, аларны билгеләү, түләү һәм илтеп тапшыруны оештыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның тугызынчы һәм унынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, аны тутыру тәртибе һәм аны электрон формада тапшыру форматы үтәлеше турында белешмә формасын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычларын салым түләүче (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан үтәү турында салым органының белешмәсен гаризага кушымта итәргә хокуклы».

Югарыда күрсәтелгән документлар кушымтасы белән гариза турыдан-туры йә ышанычлы зат аша бирелергә мөмкин. Нотариаль таныкланган гариза һәм аңа теркәлә торган документлар шулай ук дәүләт органына (Министрлыкка) почта элемтәсе оешмалары аша җибәрелергә мөмкин.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт органы ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән электрон формада, төбәк ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар барлыгы турында (булмавы турында) мәгълүматлар ала.

Дәүләт органы үзгәртеп корылган яисә бетерелгән очракта, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар барлыгы (булмавы турында) турында мәгълүматларны яңадан оештырылган яисә бетерелгән дәүләт органы функцияләре Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган дәүләт органы ала. Күрсәтелгән дәүләт органы булмаганда, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар барлыгы (булмавы турында) турында мәгълүматларны Министрлык ала.

Гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булган очракта, дәүләт органы (Министрлык) пенсиягә өстәмә түләү (тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә аңа салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларын җайга салу зарурлыгы турында хәбәр итә.»;

4.1 пунктта:

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булган очракта,

Министрлык дәүләт органы яисә граждан тарафыннан пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләү билгеләү өчен тапшырылган документларны алган көннән соң 7 көн эчендә гаризаны 90 көннән дә артык булмаган вакытка карауны туктатып тору турында карар чыгара. Министрлык гаризаны карауны туктатып тору турында карар чыгарылган көннән соң 10 көн эчендә гражданга, туктатып тору сәбәпләрен күрсәтеп, язма рәвештә хәбәр итә.»;

4.3 пунктның дүртенче абзацына түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«, пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә аның тарафыннан җайга салынмаган.»;

4.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ренсиягә өстәмә түләү (тиешле еллар эшләгән өчен пенсия) билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы җайга салынган очракта пенсиягә (тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә) өстәмә түләү билгеләү билгеләнүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән гамәлгә ашырыла. Шул ук вакытта пенсиягә өстәмә түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көн (тиешле еллар эшләгән өчен пенсияләр) дәүләт органы (Министрлык) тарафыннан гаризаны теркәү көне булып санала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин